ГЛАВА ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Декабристов, д.35 а, с. Печищи,
422592

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы,
422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　КАРАР

28.10.2019　　　　　　　　03

пос. Октябрьский

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегенең Яңа Болгар авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2019 елның 16 ноябренә Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Яңа Болгар авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. «2020 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган һәр авыл җирлеге кешесеннән 500 сум үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен алдагы эшләрне башкаруга җибәрү белән килешәсезме:

- Яңа-Болгар авылында чишмәне төзекләндерү

« ӘЙЕ»　　　　　　　　«ЮК»

3. Гражданнар җыенын Яңа Болгар авылы, Мәктәп урамы, 42 йорт адресы буенча 12.00 сәгатьтә Яңа Болгар авыл клубы янында үткәрергә.

4. Октябрьский авыл җирлеге Башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге Башлыгы　　　　　　　　Ш. Р. Азизов